| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>АЛЕКСАНДРОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>САРМАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br><br>САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>АЛЕКСАНДРОВКА АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА<br>КОМИТЕТЫ |
| --- | --- |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«18» декабрь 2025ел №35

«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Александровка авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең акчалата хезмәт хакы турында» нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

1. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль берәмлекләрнең, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, аудиторларының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органнарының депутатларның, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 25.11.2025 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» карары нигезендә районның Александровка авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Александровка авыл җирлеге башкарма комитетының 2018 елның 08 августындагы 7 номерлы карары (2018 елның 12 декабрендәге 11 номерлы, 01.10.2020 N 9 номерлы, 19.06.2024 N 13, 01.11.2024 N 30, 30.04.2025 N 15 номерлы карарлар белән) белән расланган «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Александров авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең акчалата эчтәлеге турында» нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрдән кертергә:

- 1 нче кушымтаның 2 пунктында «15 389» санын «16 928» саннарына алмаштырырга.

2. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль

берәмлегенең рәсми сайтында әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә игълан итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе
Александровка авыл җирлеге И.Ф. Вафин